МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

**от “ 14 ” сентября 2016** **№ 278**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибен раслау турында

“Россия Федерациясендә автомобилҗ транспортында һәм шәһәр җир өсте элект транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законны һәм “Россия Федерациясендә автомобилҗ транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру максатларында боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибен расларга.
2. Транспорт идарәсенең автомобиль транспорты булеге мөдире Н.Н. Доброхотовка әлеге боерыкка Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәве уздырырга.
3. Элеге боерыкның үтәлүен контрольдә тотуны транспорт идарәсе мөдире А.В. Сидоровка йокләргә.

Министр Л.Р. Сафин

Татарстан Республикасы
транспорт һәм юл
хуҗалыгы министрлыгының
2016 елның 14 сеньтябрендәге
278 номерлы боерыгы белән
расланды

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ДАИМИ РӘВЕШТӘ ПАССАЖИРЛАР ЙӨРТҮНЕҢ ҺӘМ БАГАЖ ТАШУНЫҢ МУНИЦИПАЛЬАРА МАРШРУТЛАРЫН БИЛГЕЛӘҮ, ҮЗГӘРТҮ ҺӘМ ТУКТАТУ ТӘРТИБЕ

## I.Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләүнең, үзгәртүнең һәм туктатуның әлеге Тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын (алга таба – муниципальара маршрут) билгеләү, үзгәртү һәм туктату механизмын билгели.

2. Муниципальара маршрут Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) карары белән билгеләнә, үзгәртелә яисә туктатыла.

3. Билгеләнгән яисә үзгәртелгән муниципальара маршрутлар турында белешмәләр "Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибен раслау турында" Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2016 елның 26 февралендәге 74 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары реестрына (алга таба – Реестр) кертелә һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

4. Муниципальара маршрутны билгеләү, үзгәртү яисә туктату турында карар, халык ихтыяҗыннан һәм муниципальара маршрут билгеләүнең икътисадый нигезле булуыннан (алга таба – нигезле булуы турында карар) чыгып яисә җирле үзидарә органнарының гаризасы буенча Министрлык тарафыннан кабул ителә. Территорияләреннән муниципальара маршрут уза торган муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары белән килештерелгән гариза Министрлыкка турыдан-туры китерелә, тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы хат итеп почта аша яисә, мөрәҗәгать итүченең теләге буенча, электрон имза куелган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

5. Яңа муниципальара маршрут билгеләү, алты айдан артыграк хезмәт күрсәтелмәгән гамәлдәге муниципальара маршрутны яңадан җибәрү яисә билгеләнгән муниципальара маршрутның юлын үзгәртү алдыннан комиссия

тарафыннан юл шартларының хәрәкәт иминлеге таләпләренә туры килүе тикшерелә (алга таба – юл шартларын тикшерү).

## II. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутларын билгеләү

6. Муниципальара маршрут билгеләүнең нигезле булуы турында карар кабул ителгәннән соң эш көннәрендә санала торган 30 көн эчендә Министрлык комиссия төзи һәм муниципальара маршрутның юл шартларын тикшерү үткәрә. Комиссиянең персональ составы һәм юл шартларын тикшерүне үткәрү датасы Министрлык боерыгы белән раслана. Комиссия составына территорияләреннән муниципальара маршрут уза торган җирле үзидарә органнары, автомобиль транспорты һәм юл хуҗалыгы өлкәсендә тикшереп тору һәм күзәтчелек итү органнары, ЮХИДИ органнары вәкилләре, әлеге юлны балансta тотучы һәм автомобиль юлларын карап тотуны гамәлгә ашыручы оешма вәкилләре керә.

7. Юл шартларын тикшерү тәмамланган көннән алып 5 көн эчендә муниципальара маршрутны тикшерү акты төзелә, анда комиссиянең барлык әгъзаларының имзасы салына.

8. Юл шартлары билгеләнгән юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры килгән очракта, актка муниципальара маршрут билгеләү мөмкинлеге турында язып куела.

9. Актка имза салынганнан соң эш көннәрендә санала торган 10 көн эчендә Министрлыкта муниципальара маршрут билгеләү турында боерык чыгарыла.

10. Билгеләнә торган муниципальара маршрутта юл хәрәкәте иминлегенә куркыныч тудыра торган җитешсезлекләр булуы ачыкланган очракта, актта комиссиянең хәрәкәт шартларын яхшыртуга һәм юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтүгә юнәлдерелгән чараларны кичекмәстән үткәрү зарурлыгы турындагы тәкъдиме күрсәтелә. Имза салынганнан соң эш көннәрендә санала торган өч көн эчендә актлар күрсәтелгән кимчелекләрне бетерергә вәкаләтле оешмага тапшырылырга тиеш.

11. Юл хәрәкәте иминлегенә куркыныч тудыра торган җитешсезлекләрне бетергәннән соң, Министрлыкта әлеге Тәртипнең 6 – 9 пунктларында күрсәтелгән процедуралар үткәрелә.

12. Муниципальара маршрут билгеләү турында боерык чыгарылган көннән алып эш көннәре белән санала торган 5 көн эчендә муниципальара маршрутка тәртип саны бирелә һәм аның турындагы белешмәләр Реестрга кертелә. Реестрга белешмәләр кертелгән көннән алып муниципальара маршрут билгеләнгән дип санала.

13. Министрлыкның муниципальара маршрут билгеләү турында боерыгы дәүләт контракты төзүгә ачык конкурс процедуралары яисә торглар үткәрүне оештыру өчен нигез булып тора.

14. Муниципальара маршрут җирле үзидарә органы тәкъдиме буенча билгеләнгән булса, муниципальара маршрут билгеләү турында җирле үзидарә органы тарафыннан Министрлыкка әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә гариза бирелә, ул территорияләреннән әлеге муниципаль маршрут уза торган муниципаль

берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, шулай ук, тәкъдим ителә торган муниципальара маршрут җайга салынмый торган тимер юл кичүләре аша үткән очракта, тимер юл кичүләре хуҗалары белән килештерелгән булырга тиеш.

15. Гаризага кушымта итеп аңлатма язуы бирелә, анда түбәндәгеләр булырга тиеш:

муниципальара маршрут билгеләүне нигезләү;

муниципальара маршрут буенча башлангыч тукталыш пункты һәм соңгы тукталыш пункты исемнәрен яисә әлеге муниципальара маршрут буенча башлангыч тукталыш пункты һәм соңгы тукталыш пункты урнашкан җирлекләрнең исемнәрен күрсәтеп, муниципальара маршрутның исеме;

муниципальара маршрут буенча юлдагы тукталыш пунктларының исемнәре яисә юлдагы тукталыш пунктлары урнашкан җирлекләрнең исемнәре;

даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутында тукталыш пунктлары арасында транспорт чарасының хәрәкәт итүе күз алдында тотыла торган урамнарның, автомобиль юлларының, шул исәптән график шартлы билгеләрнең тукталыш пунктлары, алар арасындагы ераклык, шулай ук характерлы ориентлашу билгеләре (юллар чишелеше, тыкрыклар, тимер юл кичүләре, күперләр һ.б.) күрсәтелгән исемнәре;

муниципальара маршрутның узуы планлаштырыла торган автомобиль юлына яисә юл участогына хезмәт күрсәтә торган оешмалар турында белешмәләр;

муниципальара маршрутның озынлыгы;

пассажирларны утырту һәм төшерү тәртибе (даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутында билгеләнгән тукталыш пунктларында гына яисә, законнар белән тыелмаган очракларда, юл хәрәкәте кагыйдәләрендә тыелмаган башка җирдә);

муниципальара маршрут буенча пассажирлар йөртү һәм багаж ташу өчен файдалану күз алдында тотылган транспорт чараларының сыйдырышлылыгы, төре, классы, экологик характеристикалары, һәрбер төрдәге транспорт чараларының максималь саны;

даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыра башлауның планлаштырылган датасы;

автобуслар хәрәкәтенең планлаштырылган расписание.

16. Тиешле гаризаны һәм кушымта итеп бирелә торган белешмәләрне теркәгән көннән алып эш көннәрендә санала торган 30 көн эчендә Министрлык җирле үзидарә органы тәкъдимен карый һәм муниципальара маршрут билгеләүнең нигезле булуы турында яисә гаризаны караудан баш тарту хакында карар кабул итә.

17. Муниципальара маршрут билгеләү турында гариза билгеләнгән рәвештә бирелмәгән булса яисә аңлатма язуында әлеге Тәртипнең 15 пунктында каралган белешмәләрнең тулы исемлеге күрсәтелмәсә, мондый гаризаны караудан баш тартыла.

18. Җирле үзидарә органы гаризасы буенча муниципальара маршрут билгеләүнең нигезле булуы турында карар кабул ителгәндә, Министрлык әлеге Тәртипнең 6 – 12 пунктларында күрсәтелгән процедураларны башкара.

19. Муниципальара маршрут билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

әлеге Тәртипнең 15 пунктында каралган белешмәләрне дөрес күрсәтмәү; муниципальара маршрутта тукталыш пунктларын җиһазлауның Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

муниципальара маршрутның Россия Транспорт министрлыгының 2014 елның 15 гыйнварындагы 7 номерлы боерыгы белән расланган Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның иминлеген тәэмин итү кагыйдәләренә туры килмәве;

муниципальара маршрут уза торган автомобиль юлларының техник торышы һәм алардагы ясалма юл корылмаларының бу муниципальара маршрут буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өчен файдалану планлаштырыла торган транспорт чараларының максималь тулы авырлыгына һәм (яисә) габаритларына туры килмәве;

транспорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен булдыру һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен башкара торган федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә ачыклана торган үткәрүчәнлек сәләте артыграк күрсәтелгән тукталыш пунктын муниципальара маршрутның тукталыш пунктлары составына кертүне тәкъдим итү.

20. Гаризаны алудан баш тарту яисә җирле үзидарә органы тәкъдиме буенча муниципальара маршрут билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә санала торган 10 көн эчендә Министрлык, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, гариза бирү ысулына бәйле рәвештә, тиешле хат җибәрә.

## III.Муниципальара маршрутны үзгәртү.

21. Муниципальара маршруттагы үзгәрешләргә түбәндәгеләр керә:

тукталыш пунктын бетерү яисә күчерү;

яңа тукталыш пункты урнаштыру;

транспорт чараларының йөрү юллары (муниципальара маршрут буенча тукталыш пунктлары арасында транспорт чаралары хәрәкәт итә торган урамнар, автомобиль юллары) үзгәрү;

муниципальара маршрут буенча пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларының классы, һәр төрдәге транспорт чараларының максималь саны үзгәрү;

муниципальара маршрутта пассажирлар утырту һәм төшерү тәртибе үзгәрү (тукталыш пунктларында гына яисә юл хәрәкәте кагыйдәләре белән тыелмаган башка җирдә);

даими пассажирлар йөртү һәм йөк ташу төре үзгәрү;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча ЮХИДИ органнарыннан әлеге муниципальара маршрутның пассажирлар йөртү иминлеген тәэмин итүнең билгеләнгән кагыйдәләренә туры килмәве турында мәгълүмат алу;

муниципальара маршрут уза торган юлны балансsucc тотучыдан бу юлдан, юлның бер генә участогыннан булса да файдалануның вакытлыча яисә тулысынча туктатылуы турында мәгълүмат алу;

тимер юл кичүе милекчесеннән бу тимер юл кичүе аша автомобиль транспорты хәрәкәтенең вакытлыча яисә тулысынча туктатылуы турында мәгълүмат алу.

22. Муниципальара маршрутны үзгәртүнең нигезле булуы турында Министрлык тарафыннан карар кабул ителгән көннән алып эш көннәре белән санала торган 15 көн эчендә муниципальара маршрутны үзгәртү турында боерык чыгарыла. Муниципальара маршрут турында белешмәләр Реестрга кертелә.

23. Муниципальара маршрут җирле үзидарә органы тәкъдиме белән үзгәртелгән очракта, муниципальара маршрутны үзгәртү турында җирле үзидарә органы тарафыннан Министрлыкка әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендә гариза бирелә, ул территорияләреннән үзгәртелә торган әлеге муниципаль маршрут узучы муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, әлеге муниципальара маршрут билгеләүне тәкъдим иткән җирле үзидарә органы, шулай ук, үзгәртелә торган муниципальара маршрут җайга салынмый торган тимер юл кичүләре аша үткән очракта, тимер юл кичүләре хуҗалары белән килештерелгән булырга тиеш.

24. Муниципальара маршруттагы үзгәрешләрне нигезли торган аңлатма язуы, әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә тиешле үзгәрешләрнең исемлеге гаризага кушымта итеп бирелә.

25. Тиешле гаризаны һәм кушымта итеп бирелә торган белешмәләрне теркәгән көннән алып эш көннәре белән санала торган 30 көн эчендә Министрлык җирле үзидарә органы тәкъдимен карый һәм муниципальара маршрутны үзгәртүнең нигезе булуы турында яисә гаризаны караудан баш тарту хакында карар кабул итә.

26. Муниципальара маршрутны үзгәртү турындагы гариза билгеләнгән рәвештә тапшырылмаса, аны караудан баш тартыла.

27. Муниципальара маршрут уза торган юл үзгәрү сәбәпле муниципальара маршрутны үзгәртүнең нигезле булуы турында карар кабул ителгәндә, Министрлык әлеге Тәртипнең 6 – 12 пунктларында каралган процедураларны үткәрә.

28. Муниципальара маршрутны үзгәртүдән баш тарту өчен нигезләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

гаризада яисә кушымта итеп бирелүче исемлектә әлеге Тәртипнең 24 пунктында күрсәтелгән белешмәләрнең дөрес бирелмәве;

муниципальара маршрут параметрларының пассажирлар ташу иминлеген тәэмин итүнең билгеләнгән таләпләренә туры килмәвенә китерә торган үзгәрешләр;

әлеге муниципальара маршрут узу планлаштырыла торган урамнарның, автомобиль юлларының техник торышы һәм алардагы ясалма юл корылмаларының бу муниципальара маршрут буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өчен файдалану күздә тотыла торган транспорт чараларының максималь тулы авырлыгына һәм (яисә) габаритларына туры килмәве;

әлеге муниципальара маршрут составына кертелгән тукталыш пунктларының үткәрүчәнлек сәләте туры килмәү яисә аларны арттырып күрсәтү;

территориясендә бу муниципальара маршрутның тукталыш пунктлары урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге халкы ихтыяҗлары тәэмин ителмәсә, әлеге муниципальара маршруттагы тукталыш пунктларын бу муниципальара маршруттан төшереп калдыру;

территориясендә бу муниципальара маршрутның тукталыш пунктлары урнашкан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге халкы ихтыяҗлары тәэмин ителмәсә, әлеге муниципальара маршрутта даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларының санын һәм (яисә) сыйдырышлылыгын киметү.

29. Муниципальара маршрутны үзгәртү турында тәкъдим керткән җирле үзидарә органына гаризаны кабул итүдән баш тарту яисә муниципальара маршрутны үзгәртүдән баш тарту турында карар кабул ителү хакында хәбәр итү әлеге Тәртипнең 20 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

## IV. Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципальара маршрутын туктату

30. Вәкаләтле орган түбәндәге очракларда муниципальара маршрутны туктата:

әлеге муниципальара маршрутка халыкның ихтыяҗы булмау;

ике яисә аннан артыграк муниципальара маршрутны берләштерү;

“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2016 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясындагы 7 өлешендә күрсәтелгән нигезләрдә ачык конкурсны үткәрелмәде дип тану һәм ачык конкурсны икенче кабат үткәрмәү турында карар кабул итү;

ачык конкурс процедуралары йә торглар кабат үткәрелгән очракта Министрлыкка даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм йөк ташуны җайга салынмый торган тарифлар буенча гамәлгә ашыру теләге булган юридик затлардан, индивидуаль эшкуарлардан, гади ширкәт шартнамәсендә вәкаләтле катнашучылардан ачык конкурста катнашу өчен заявкалар яисә даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм йөк ташуны җайга салынмый торган тарифлар буенча гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга дәүләт контракты төзү өчен торгларда катнашуга гаризалар кермәү;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча ЮХИДИ органнарыннан әлеге муниципальара маршрутның пассажирлар йөртү иминлеген тәэмин итүнең билгеләнгән кагыйдәләренә туры килмәве турында мәгълүмат алу;

Министрлыкка муниципальара маршрут уза торган урамнарның һәм автомобиль юлларының техник торышы һәм алардагы ясалма юл корылмаларының бу муниципальара маршрут буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм йөк ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларының максималь тулы авырлыгына һәм (яисә) габаритларына туры килмәве турында мәгълүмат керү;

әлеге муниципальара маршрутка кертелгән урамнар һәм автомобиль юллары хуҗаларыннан, бу муниципальара маршрутка кертелгән тукталыш пунктлары урнашкан автовокзаллар һәм автостанцияләр хуҗаларыннан әлеге муниципальара маршруттагы тукталыш пунктларының үткәрүчәнлек сәләте артыграк күрсәтелү турында мәгълүмат керү;

җирле үзидарә органнары гаризасы буенча.

31. Муниципальара маршрутны туктатуның нигезле булуы турында Министрлык тарафыннан карар кабул ителгән көннән алып эш көннәре белән санала торган 15 көн эчендә муниципальара маршрутны туктату турында карар кабул ителә. Туктатылган муниципальара маршрут турындагы белешмәләр Реестрдан төшереп калдырыла.

32. Муниципальара маршрут җирле үзидарә органы тәкъдиме белән туктатылган очракта, җирле үзидарә органы муниципальара маршрутны туктату турында Министрлыкка әлеге Тәртипнең 4 нче кушымтасы нигезендә гариза тапшыра, ул территорияләреннән әлеге муниципальара маршрут уза торган муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән килештерелгән булырга тиеш.

33. Муниципальара маршрутны туктату турындагы гаризага муниципальара маршрутны туктатуны нигезли торган аңлатма язуы кушымта итеп бирелә.

34. Тиешле гаризаны һәм кушымта итеп бирелә торган белешмәләрне теркәгән көннән алып эш көннәре белән санала торган 30 көн эчендә Министрлык җирле үзидарә органы тәкъдимен карый һәм муниципальара маршрутны туктатуның нигезле булуы турында яисә гаризаны караудан баш тарту хакында карар кабул итә.

35. Муниципальара маршрутны туктату турындагы гаризаны караудан түбәндәге очракларда баш тартыла:

гаризаның билгеләнгән рәвештә бирелмәве;

муниципальара маршрутны туктату турындагы тәкъдимнең нигезләнмәгән булуы;

әлеге муниципальара маршрут уза торган территориядәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге халкының ихтыяҗлары тәэмин ителүгә карамастан, муниципальара маршрутны туктату турында тәкъдим кертү.

36. Җирле үзидарә органнары гаризасы буенча муниципальара маршрутны туктатуның нигезле булуы турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәре белән санала торган 15 көн эчендә муниципальара маршрутны туктату турында карар кабул ителә. Туктатылган муниципальара маршрут турындагы белешмәләр Реестрдан төшереп калдырыла.

37. Муниципальара маршрутны үзгәртү турында тәкъдим керткән җирле үзидарә органына гаризаны кабул итүдән баш тарту яисә муниципальара маршрутны үзгәртүдән баш тарту турында карар кабул ителү хакында хәбәр итү әлеге Тәртипнең 20 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

38. Муниципальара маршрутны туктату турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык тиешле муниципальара маршрут буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм йөк ташуны гамәлгә ашыра торган юридик затка, индивидуаль эшкуарга, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыга әлеге карар үз көченә кергән көннән алып йөз сиксән көннән дә соңга калмыйча бу карар турында хәбәр итәргә тиеш.

39. Әлеге муниципальара маршрутка кертелгән тукталыш пунктлары хуҗалары бу муниципальара маршрутны туктату турында Министрлыктан хәбәр

алынган көннән алып өч көннән дә соңга калмыйча муниципальара маршрутның туктатылуы хакында тукталыш пунктларында мәгълүмат урнаштырырга тиеш.

Татарстан Республикасы территориясендә
даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм
багаж ташуның муниципальара маршрутларын
билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгына
_________________________________
(җирле үзидарә органы исеме)

**Муниципальара маршрут билгеләү турында гариза**

Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм йөк ташу буенча Татарстан Республикасы
_______________________________________________________________________________
(муниципаль берәмлекләр исеме)
территориясе буенча уза торган
_______________________________________________________________________________,
(маршрутның исеме)
муниципальара автобус маршруты билгеләүне сорыйбыз.

Кушымта:__ б. __ н.

Татарстан Республикасы
__________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
Башкарма комитеты җитәкчесе ____________ (______________________)
(имза) (тулысынча)

М.У.

Килештерелде:

Татарстан Республикасы
__________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
Башкарма комитеты җитәкчесе ____________ (______________________)
(имза) (тулысынча)

Татарстан Республикасы территориясендә
даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм
багаж ташуның муниципальара маршрутларын
билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгына
______________________________
(җирле үзидарә органы исеме)

**Муниципальара маршрут үзгәртү турында гариза**

Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм йөк ташу буенча Татарстан Республикасы
______________________________________________________________________________
(муниципаль берәмлекләр исеме)
территориясе буенча уза торган ____ номерлы
______________________________________________________________________________,
(маршрутның исеме)
муниципальара автобус маршрутын үзгәртүне сорыйбыз.

Кушымта:__ б. __ н.

Татарстан Республикасы
______________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
Башкарма комитеты җитәкчесе _____________ (_______________________)
(имза) (тулысынча)

М.У.

Килештерелде:

Татарстан Республикасы
______________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
Башкарма комитеты җитәкчесе _____________ (_______________________)
(имза) (тулысынча)

Татарстан Республикасы территориясендә
даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм
багаж ташуның муниципальара маршрутларын
билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибенә
3 нче кушымта

"_______________________________________" _____ номерлы
даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара
маршруты үзгәрешләре чагыштырма таблицасы

| № т/с | Муниципальара маршрутның билгеләнгән параметрлары | Муниципальара маршрутны үзгәртү тәкъдимнәре | Кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып муниципальара маршрутның параметрлары |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |

Татарстан Республикасы территориясендә
даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм
багаж ташуның муниципальара маршрутларын
билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибенә
4 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл хуҗалыгы
министрлыгына
______________________________
(җирле үзидарә органы исеме)

**Муниципальара маршрут туктату турында гариза**

Даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм йөк ташу буенча Татарстан Республикасы
________________________________________________________________
(муниципаль берәмлекләр исеме)
территориясе буенча уза торган ____ номерлы
________________________________________________________________,
(маршрутның исеме)
муниципальара автобус маршрутын үзгәртүне сорыйбыз.

Кушымта:__ б. __ н.

Татарстан Республикасы
______________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
Башкарма комитеты җитәкчесе _____________ (_______________________)
(имза) (тулысынча)

М.У.

Килештерелде:

Татарстан Республикасы
______________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
Башкарма комитеты җитәкчесе _____________ (_______________________)
(имза) (тулысынча)